ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяда:

а) өченче абзацта “, федераль башкарма хакимият органнары җитәкчеләре белән килештереп,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта “федераль башкарма хакимият органнары белән килештереп,” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа егерме җиденче һәм егерме сигезенче – утыз алтынчы абзацлар өстәргә:

“җитештерү һәм куллану калдыклары (алга таба шулай ук – калдыклар) белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашырганда килеп чыккан табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларын үткәрү;

калдыклар барлыкка китерү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын, региональ дәүләт экология күзәтчелегендә булган объектларда калдыкларны барлыкка китергәндәге юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның (кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан тыш) хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлегенә карата калдыклар барлыкка китерү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын эшләү һәм раслау тәртибен билгеләү;

региональ дәүләт экология күзәтчелегендә булган объектларда хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлек барышында калдыкларны барлыкка китерә торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан хәбәр итү тәртибендә тапшырыла торган

калдыкларны барлыкка китерү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру турындагы хисаплылыкны кабул итүне гамәлгә ашыру һәм аны тапшыру һәм тикшереп тору тәртибен билгеләү;

калдыкларның региональ кадастрын алып бару тәртибен, каты коммуналь калдыкларны туплау нормативларын билгеләү;

каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә чик тарифларны, каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибен раслау;

каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча операторларның инвестиция программаларын һәм житештерү программаларын раслау;

каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю), транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү эшчәнлеген оештыру;

калдыклар, шул исәптән каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасын эшләү һәм раслау;

каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторны конкурслы сайлап алуны үткәрү тәртибен билгеләүдән тыш, аның эшчәнлеген җайга салу;

каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ операторны конкурслы сайлап алуны үткәрү, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ оператор белән килешүнең эчтәлеген һәм аны төзү тәртибен, шулай ук каты коммуналь калдыкларны җыюны һәм транспортировкалауны гамәлгә ашыруга торглар уздыру шартларын билгеләү;";

б) егерме җиденче абзацны утыз җиденче абзац дип санарга;

3) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Экология өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнары федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган экология өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.";

4) 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"21 статья. **Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә нормалаштыру**

Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә нормалаштыру "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.";

5) 34 статьяның 3 пунктында “калдыкларны зарарсызландыру, урнаштыру” сүзләрен “I – IV классны хәвефлелектәге калдыкларны җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру” сүзләренә алмаштырырга;

6) 142 статьяда:

а) 1 өлештә түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 пунктлар өстәргә:

“7) ял итү урыннары;

8) табигать микрозаказниклары.”;

б) 3 өлештә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Ял итү урыннары һәм табигать микрозаказниклары җирле әһәмияттәге махсус саклануочы табигать территорияләренә керәләр.”;

7) түбәндәге эчтәлекле $157^1$ статья өстәргә:

“$157^1$ статья. **Ял итү урыннары**

1. Чикләрендә ял итү һәм туризм өчен файдаланыла торган һәм шәһәр урманнары, скверлар, парклар, бакча-парк ансамбльләре булган җир кишәрлекләре урнашкан җирле әһәмияттәге махсус саклануочы табигать территорияләре ял итү урыннары була.

2. Ял итү урыннары, аларны махсус саклау һәм алардан файдалану режимы турындагы нигезләмә җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана.”;

8) түбәндәге эчтәлекле $157^2$ статья өстәргә:

“$157^2$ статья. **Табигать микрозаказниклары**

1. Чикләрендә кыргый хайваннар тереклек итү һәм аерым кыйммәткә ия үсемлекләр төрләре үсү, кыргый хайваннарның сирәк һәм юкка чыгып баручы төрләрен, билгеле бер урында таралган үсемлекләрнең төрләрен саклау өчен аеруча әһәмиятле җир кишәрлекләре, шулай ук махсус табигатьне саклау әһәмиятенә ия, фәнни, мәдәни, эстетик әһәмияткә ия аерым урнашкан табигать объектлары булган җир кишәрлекләре урнашкан җирле әһәмияттәге махсус саклануочы табигать территорияләре табигать микрозаказниклары була.

2. Табигать микрозаказниклары, аларны махсус саклау һәм алардан файдалану режимы турындагы нигезләмәләр җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана.”;

9) 161 статьяның 1 өлешендә “файдаланылган” сүзен “утильләштерелгән” сүзенә алмаштырырга;

10) 162 статьяда “җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүче эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлар” сүзләрен “җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка китерә торган хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлекне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарлар, юридик затлар” сүзләренә алмаштырырга;

11) 164 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“164 статья. **I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү**

I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү “Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында” 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә “Җитештерү һәм куллану калдыклары турында” 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.”;

12) 166 статьяда:

а) исемендә “I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны” сүзләрен “Җитештерү һәм куллану калдыкларын” сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә:

беренче абзацта “I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны” сүзләрен “Җитештерү һәм куллану калдыкларын” сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта “I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларның” сүзләрен “җитештерү һәм куллану калдыкларының” сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта “I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны” сүзләрен “җитештерү һәм куллану калдыкларын” сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта “I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны” сүзләрен “җитештерү һәм куллану калдыкларын” сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Калдыкларның төренә һәм калдыкларның хәвефлелек классына карап, калдыкларны төяү-бушату эшләренә, аларны маркировкалауга, экологик иминлекне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә дифференциацияләнгән таләпләр карала торган I – IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны транспортировкалау тәртибе, федераль башкарма хакимиятнең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыручы органы белән килештереп, федераль башкарма хакимиятнең транспорт өлкәсендәге органы тарафыннан билгеләнә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 12 гыйнвары
№ 1-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ